КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 июль г.Казань № 583

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 апрель, 226 нчы карары белән расланган 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 апрель, 226 нчы карары белән расланган 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субвенцияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы (алга таба – җирле үзидарә органы) арасында Министрлык тарафыннан расланган бертип форма нигезендә килешү (алга таба – килешү) төзелә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субвенцияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органы өчен ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин